ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**Постановление** **_Карар_**

**18.12.2025** **Чистай шәһәре** **№ 621**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 08 декабрендәге 643 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклыкны исәпкә кую һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.10.2023 № 1209, 04.10.2023 № 1232, 15.06.2024 № 430 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 08 декабрендәге 643 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү алу хокукы турында таныклыкны исәпкә кую һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 2.5 пунктындагы "в" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"в) чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;";
1.2. 2.5 пунктның "2" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"2) чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;";

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://chistopol.tatarstan.ru).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов